№7

апрель

Казан Кибәхуҗа төп мәктәбендә нәшер ителүче айлык газета

# Көмеш кыңгырау

Газетаның электрон версиясе белән мәктәп сайтында таныша аласыз

**Игътибарыгызны юнәлтегез:**

- 7 апрель көнне Казан шәһәренең 102 номерлы мәктәбендә “Ватаным сагында” дип исемләнгән II республика күләмендә үткәрелгән рәсем конкурсы җиңүчеләрен бүләкләү тантанасы булып үтте. Бүләкләнүчеләр арасында безнең мәктәпнең 8 сыйныф укучысы Сафиуллина Илүзә (җитәкчесе-Шаипова Р.И.) дә бар. Ул II урынны яулап Диплом белән бүләкләнде.
- 8 апрель көнне “Батыр” спорткомплексында армспорт буенча Хәким Хәдиуллин призына Теләче муниципаль районы беренчелеге булып үтте. Бу бәйгедә 70 кг авырлыкта көч сынашып, 8 нче сыйныф укучысы Шангараев Рушан II урын, ә кызлар арасыннан 9 нчы сыйныф укучысы Гыйльметдинова Гөлшат (тренерлары- Р.Г. Даутов) II урынны яулады. Котлыйбыз!
- 10 апрель көнне район мәдәният йортында Бөек Җиңүнең 69 еллыгына багышлап үткәрелгән хәрби-патриотик смотр-конкурсында безнең мәктәп укучылары (җитәкчесе-Шаипова Р.И.) “Хореография”номинациясендә катнашып III урынга лаек булдылар.

**Бу санда:**


| | |
|---|---|
| 1 апрель—Халыкара кошлар көне | 2 бит |
| 12 апрель-Космонавтика көне көне- | 3 бит |
| 15 апрель-Халыкара мәдәният көне | 3 бит |
| Башлангыч сыйныфларда атналык | 4-5 бит |
| Габдулла Тукайның тууына-128 ел | 6 бит |
| Район күләмендә семинар-киңәшмә | 7 бит |
| Котлаулар | 8 бит |


## Мәктәбебез яңалыклары

3 апрель көнне мәктәптә "Балалар катнашында җинаятьчелекне кисәтү" темасына әти- әниләр җыелышы булып үтте.Әти- әниләр каршында Теләче эчке эшләр бүлекчәсендә балигъ булмаганнар арасында җинаятьчелекне кисәтү, булдырмау, профилактикалау буенча инспектор Р.Р.Нәҗмиева чыгыш ясады. Ул үз чыгышында республикада, районыбызда балалар катнашында булган җинаятьләрне анализлап үтте, Гаилә Кодексының 61,67 нче матдәләрендә күрсәтелгән таләпләр , Җинаятьләр Кодексы, Административ Кодексның кайбер матдәләре белән таныштырды,2010 елда чыккан 71нче Закон таләпләрен искә төшерде. "Закон алдында балалар өчен ата- ана җавап бирә, шуны онытмасагыз иде",- дип йомгаклады ул үзенең сүзен.

1 апрельдән мәктәптә Хезмәтне саклау айлыгы башланды. Айлык дәвамында янгынга, экстремизмга каршы, юл йөрү кагыйдәләре буенча күптөрле чаралар планлаштырылган.Шул уңайдан 9 апрель көнне 8 нче сыйныф җитәкчесе Галимҗанова Г.Ә. "Юлларда куркынычсызлык кагыйдәләрен үтик" дигән темага балалар иртәсе үткәрде. Укучыларга аеруча велосипедта, транспортта йөрү, җәяүлеләр өчен кагыйдәләр кабат аңлатылды. Соңыннан тема буенча викторина үткәрелде.

Олы Кибәхуҗа башлангыч мәктәбенең 1 сыйныф укучысы Муликова Диана (укытучы Шәяхмәтова И.Р.) һәм безнең мәктәпнең 3 сыйныф укучысы Гыймадиев Илүс (укытучы Гарипова Г.З.)"Русский медвежонок- языкознание для всех" дип исемләнгән халыкара уен-конкурсында катнашып, Диплом һәм Сертификатка ия булдылар.

14-19 апрель көннәрендә мәктәбебездә башлангыч сыйныфларның математика атналыгы булып үтте. Атналык математика елына багышланды. (Атналыкның барышы белән газетабызның 4-5 битләреннән тулырак таныша аласыз).

17 апрель көнне мәктәбебезнең барлык классларында да Халыкара урман көненә багышланган сыйныф сәгатьләре үткәрелде. Укучылар урманның файдасы турында сөйләделәр һәм аны саклау чаралары буенча фикер алыштылар.

24 апрель көнне мәктәбебездә районның математика укытучылары семинары булып узды. Тулырак бу хакта газетабызның 7 битеннән укып белә аласыз.

Язгы, җәйге чорда янгын чыгу очракларының кискен артуы һәм аларда үлүчеләрнең саны күбәю сәбәпле Татарстан Республикасы территориясендә 20 апрельдән 15 майга кадәр янгынга каршы режим урнаштырылды. Әлеге режим кысаларында гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы янгын куркынычсызлыгы буенча комплексы эш алып бара. 25 апрель көнне ОДН инспекторы Мухаметзянов Фиргать Тәлгатович мәктәбебезгә килеп укучылар белән очрашу уздырды, янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен кабат аңлатты һәм 9нчы сыйныф укучылары белән анкетлаштыру уздырды.

25 апрель көнне мәктәбебезнең 8 сыйныф укучысы Даутова Дилбәр (җитәкчесе Галимҗанова Г.Ә.) Байлар Сабасында үткәрелгән I зона фәнни-гамәли конференциясендә “Бөек Ватан сугышы: саннар һәм фактлар” темасы астында чыгыш ясап, Сертификатка ия булды.

29 апрель көнне мәктәбебезнең тарих укытучысы Рахматуллина Айгөл Әбүзәровна Россияне, Кырым Республикасын һәм Севастопольне интеграцияләштерүгә багышланган «Без бергә!» темасы буенча Парламент дәресе үткәрде.


Министерство образования и науки Республики Татарстан

СЕРТИФИКАТ

участника II республиканских педагогических чтений имени татарского просветителя, педагога и общественного деятеля Мухлисы Буби

учителя начальных классов Малокибякозинской ООШ Тюлячинского муниципального района РТ

Гариповой Гульсины Зулфаровны

Заместитель премьер - министра Республики Татарстан - министр образования и науки Республики Татарстан

Э.Н. Фаттахов

3 апреля 2014 года

Казань

3 апрель көнне мәктәбебезнең башлангыч сыйныф укытучысы Гарипова Г.З. күренекле татар мәгърифәтчесе, педагог һәм җәмгыять эшлеклесе Мөхлисә Буби исемендәге 2 республика педагогик укуында катнашып, Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгының Сертификатына ия булды.

# Габдулла Тукайның туувына - 128 ел



**Татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукай дөньяда нибары 27 ел яшәгән, бары тик 8 ел иҗат иткән - шулай да гасырларга җитәрлек рухи байлык калдырган. Аның исемен һәркем яхшы белә. Ул зурлар өчен дә, кечкенәләр өчен дә бик күп шигырьләр язган. Балалар аның шигырьләрен яратып укыйлар.**

## Бәләкәй Тукай

**Габдулла Тукай 1886 елның 26(14) енче апрелендә хәзерге Арча районы Кушлавыч авылында мулла гаиләсендә туган. Тууына алты ай булганда атасы Мөхәммәтгариф, дүрт яшендә анасы Мәмдүдә дә үлеп, булачак шагыйрь бөтенлә ятим кала. Аңа йорттан йортка күчеп гомер итәргә туры килә.**



**Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенең быелгы лауреатлары исемнәре билгеле булды.**

**Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов 2014 елда Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясен бирү турындагы Указны имзалады. Татарстанның ике мәдәният эшлеклесе лауреат булды. Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе <u>“Утлы дала” ике томлы тарихи романы</u> өчен язучы Вахит Имамовка һәм каллиграфик композицияләре өчен Владимир Поповка бирелә.**

## Викторина сораулары

**Бу өзекләр Г.Тукайның кайсы шигырьләреннән?**

1. Әйдәле, Акбай! өйрән син, арт аягың берлә тор;
Аума, аума!туп-туры тор,төз утыр, яхшы утыр!
Ник газаплыйсың болай син, мин әле бик кечкенә;
Мин туганга тик ике айлап булыр, йә өч кенә.

2.Бервакыт китәм дигәнд, төште күзем басмага;
Карасам: бер куркыныч хатын утырган басмада.
Көнгә каршы ялтырый куындагы алтын тарак,
Шул тарак берлә утыра тузгыган сачын тарап.
Тын да алмыйча торам, куркып кына, тешне кысып
Шунда яр буендагы куе агачларга посып.

3. Кәҗә әйтә: “Кайгырмагыз, бездә ит күп;
Ул ит белән һәр кайсыбыз булырбыз тук!
Ни карыйсың? Тиз бул әле,тиз бул сарык !
Капчыктагы бүре башын китер алып.”
Кәҗә әйтә: “Микикики! Микикики!
Капчыктагы бүре башы бит уники”

4.“Кысты , Хәрап итте явыз
“Былтыр мине, ah , үләм бит,
бу бәләдән кем килеп йолкыр мине?”

5. Әлли –бәлли итәр бу,
Мәдрәсәгә китәр бу ,
Тырышып сабак укыгач,
Галим булып җитәр бу.


# 12 апрель – Космонавтика көне



1961 елның 12 апрель көнне безнең ил гражданины хәрби очучы Юрий Алексеевич Гагарин галәмгә очты. Аның «Восток» корабле Җир шарын тирәли 108 минута әйләнеп чыкты һәм туган җиренә исән-имин әйләнеп кайтты.

Урта һәм өлкән буын Гагаринны яхшы хәтерли. Безнең өчен, ягъни урта буын вәкилләренә ул – үрнәк, аның кебек булырга тырышу, омтылыш идеалы булса, өлкән буын беренче тапкыр космоска аяк баскан Юрий Гагаринны, 1961 елның 12 апрелен яңа эпоха башлануы итеп кабул иткән иде. Бу очу бөтен дөнья өчен зур сенсация була – безнең ил Американы узып китте! Галәмдәге тәүге кеше – безнең илдән!

## Җирнең ясалма иярченнәре



Спутник –1

**1957 елның 4 октябрь көнендә Җирнең беренче ясалма иярчене - «Спутник-1» галәмгә җибәрелде.**



«Спутник – 2»

1957 елның 3 ноябрь көнендә Җирнең икенче ясалма иярчене - «Спутник-2» галәмгә җибәрелде. Аның кабинасында кечкенә пассажир- Лайка исемле эт тә бар иде.

## 15 апрель—Халыкара мәдәният көне

15 апрель—Халыкара мәдәният көне. Ул 1999 елдан билгеләп үтелә. 2014 ел - Русиядә һәм Татарстанда Мәдәният елы итеп игълан ителде. Бу исә әлеге тармак хезмәткәрләре алдына зур бурычлар куя. Татарстанда мәдәниятне үстерү буенча 2014-2020 елларга исәпләнгән закон кабул ителде. Мәдәниятнең мөһим тармак икәнен узган ел Казанда булып үткән XXVII Бөтендөнья Универсиадасы да раслады. Бу чараны ачу һәм ябу тантаналарында, кунаклар катнашында бәйрәм ителгән шәһәр Сабан туенда, Универсиада авылы янындагы аерым мәйданчыкларда йөзләгән сәнгать коллективлары уңышлы чыгыш ясады. Кунаклар һәм спортчылар республикабыз мәдәниятен төрле яклап манзара кыла алды.

“ТЮРКСОЙ” оешмасы карары белән 2014 ел Казан төрки дөньяның мәдәни башкаласы дип игълан ителде. Бу безнең уңышларның халыкара масштабта танылуы турында сөйли һәм Татарстан Мәдәният министрлыгына зур җаваплылык өсти. Алда республикабыз мәдәниятен төрки дөньяга лаеклы рәвештә күрсәтү бурычы тора.

Шул уңайдан 2 апрель көнне рус теле һәм әдәбияты укытучысы Арсланова И.М. “ХХ гасырның беренче яртысында мәдәният” темасына иртә үткәрде. Укучылар Татарстан Республикасында үткәрелгән Халыкара фестиваль һәм конкурслар турында сөйләделәр. Аннан соң Илмира Мансуровна презентация ярдәмендә үткән гасыр сәнгатендәге юнәлешләрне анализлады.

# Туган көннәрегез котлы булсын!

**Рече Кибәхуҗа төп мәктәбендә озак еллар тәмле ашлар пешерүче булып эшләгән Закирова Фәймә Васил кызын 60 яшьлек юбилее һәм Кече Кибәхуҗа төп мәктәбенең IX сыйныф укучысы Гыйльметдинова Гөлшатны туган көннәре белән котлыйбыз! Сезгә нык сәламәтлек, озын гомер, ак бәхетләр, күп шатлыклар телибез.**

**КОТЛЫЙБЫЗ!**



**Җылы якты язда тугансыз-**
**Яз кояшы сезнең күңелдә.**
**Бәхет, шатлык, куанычлар белән**
**Яшәгез сез гомер—гомергә!**
**Авырлыклар бер дә кичермәгез,**
**Кыенлыклар бер дә килмәсен.**
**Сезнең йөзегездә шатлык нуры,**
**Балкып торсын, мәңге сүнмәсен!**



Малокибякозинская ООШ

**Газетаны гамәлгә куючы:**
**ТР Теләче муниципаль районы Кече Кибәхуҗа төп мәктәбе администрациясе**
**Баш мөхәррир:**
**I, III сыйныф җитәкчесе**
**Г.З.Гарипова**

**Безнең адрес:**
**422080, Теләче районы, Кече Кибәхуҗа авылы, Кече урам, 10 нчы йорт.**
**Белешмәләр өчен телефон:**
**56 – 2 – 40**
**e-mail: mkibiakozi40@mail.ru**